СОВЕТ
НОВОИЛЬМОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА ЭЛМӘЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

с.Новое Ильмово

2020 нче елның 03 июне № 66/3

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлеге территориясендә ачык тыңлаулар оештыру һәм үткәрү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2017 елның 29 декабрендә кабул ителгән 455-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» гы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлеге Советының 16.04.2012 ел, № 16/3 карары (30.11.2012 ел № 21/4, 16.10.2018 ел, № 42/3 редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлеге территориясендә ачык тыңлаулар оештыру һәм үткәрү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә:

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Ачык тыңлаулар халык, авыл җирлеге Советы, авыл җирлеге башлыгы, авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе инициативасы белән үткәрелә.»;

4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Халык яки авыл җирлеге Советы инициативасы белән үткәрелә торган ачык тыңлаулар авыл җирлеге Советы, ә авыл җирлеге башлыгы яки авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе инициативасы белән контракт нигезендә үз вәкаләтләрен башкаручы авыл җирлеге башлыгы тарафыннан билгеләнә.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы сайтында авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга.

Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль районы Яңа Элмәле
авыл җирлеге башлыгы: Р.Н. Дружков